| | |
|---|---|
| ГЛАВА<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«МУКМИН-КАРАТАЙСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«МӨЭМИН-КАРАТАЙ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

30 октябрь 2020 ел № 1

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Мөэмин-Каратай авыл җирлегенең Мөэмин-Каратай авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Лениногорск муниципаль районы Мөэмин-Каратай авыл җирлеге Уставы нигезендә, Лениногорск муниципаль районы Мөэмин-Каратай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы КАРАР БИРДЕ:

1. Лениногорск муниципаль районы Мөэмин-Каратай авыл җирлегенең Мөэмин-Каратай авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2020 елның 13 ноябренә 16 сәгать 00 минутта билгеләргә.

2.Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Сез 2021 елда үзара салым кертүне Лениногорск муниципаль районының Мөэмин-Каратай авыл җирлегенең Мөэмин-Каратай авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 һәм 2 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннары, Бөек ватан сугышы ветераннарының тол хатыннары, тыл хезмәтчәннәреннән тыш, алынган средстволарны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкаруны хәл итүгә юнәлдерүгә 500 сум күләмендә билгеләү белән килешәсезме:

-Авыл җирлеге чикләрендә җирле әһәмияттәге юлларга карата юл эшчәнлеге
- Мөэмин-Каратай авылы юлларына ремонт ясау.

« ӘЙЕ» «ЮК».

3. Әлеге карарны Мөэмин-Каратай авылы, Механизаторлар урамы, 31Б буенча урнашкан мәгълүмат стендында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә (http://leninogorsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Лениногорск муниципаль районы
«Мөэмин-Каратай авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы
вазифаларын башкаручы Г.Г.Хәкимов